РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ МИЧАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422055, Республика Татарстан, Сабинский район,
Село Старый Мичан , ул. Школьная, 12
тел. (84362) 42-3-31

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МИЧЭН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422055, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Иске Мичэн авылы, Мэктэп урамы, 12 йорт
тел. (84362) 42-3-31

e-mail: mich.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
19.12.2023

КАРАР
№35

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Советының 08.11.2021 №22 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Тәкъдим ителгән куркыныч индикаторлары турында Татарстан Республикасы икътисад Министрлыгының 12.10.2023 елның 01-54/7098 номерлы хатын караганнан соң, Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Советының 08.11.2021 елның №22 «Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә (алга таба текст буенча – Нигезләмә) түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1.Кушымта нигезендә 2 нче кушымтаны яна редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/michan адресы буенча һәм җирлекнең махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Мичән авыл
җирлеге Башлыгы

А.Ә.Гәрәев

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Мичән
авыл җирлеге Советының 19.12.2023 елгы 35
номерлы карарына Кушымта

«Кушымта 2
Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Мичән авыл җирлеге чикләрендә
муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә

Муниципаль контроль үткәргәндә контроль чаралар үткәрү өчен нигез буларак кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары

1. Муниципаль торак фондының торак бипалары булган күпфатирлы йортта, көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча карарлар булган, милекчеләрнең гомуми җыелышының ике һәм аннан да күбрәк беркетмәсен өч ай рәттән муниципаль торак контроле органына кертү.

2. Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматларына караганда, контрольдә тотылган зат идарәсендә күп фатирлы йортта гомуми милектәге җитешсезлекләрне бетерү буенча эшләр башкару өчен атнага биштән артык ремонт бригадасы чакырыла.

3. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү документларында күпфатирлы йорт милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдаланганда һәм тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләмен алдагы шундый ук исәп-хисап чоры белән чагыштырганда 50% тан артык арттыру турында белешмәләрне ачыклау.»